ГЛАВА ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның "16" октябреннән № 4

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Өргәнче авылында гражданнар җыенын билгеләү турында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 29 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Өргәнче авыл клубында (Яңа урамы, 24 йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылында Зирекле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылында Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда үзара салым кертүгә сез, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларның юлламасы белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү өчен башка урыннар) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru., «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре

порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Өргәнче авылының Яңа урамындагы мәгълүмат стендында, 5 нче йорты янында гражданнар җыены уздырылганчы 10 көннән дә соңга калмыйча.

5. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы                    Җ.Г. Гайфетдинов